**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районының «Лашман авыл җирлеге»**
**муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре**
проекты буенча фикер алышу буенча гавами тыңлауларның
**5 нче номерлы БЕРКЕТМӘСЕ**

**Үткәрү датасы һәм вакыты:** 21.07.2026 ел, 15:00 сәгать.
**Рәсмиләштерү урыны:** Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Лашман авыл җирлеге Башкарма комитеты бинасы, адресы: ТР, Чирмешән районы, Лашман авылы, Совет урамы, 55А йорты

Гавами тыңлаулар Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы «Лашман авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлаулар уздыруны билгеләү турында» 01.07.2026 №208 карары белән билгеләнде, түбәндәгеләрдә бастырылды:

- Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) - 02.07.2026 ел;
- Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында (https://cheremshan.tatarstan.ru/pravila-zemlepolzovaniya-i-zastroyki-lashmanskogo-9004329.htm ) - 02.07.2026 ел.

**Гавами тыңлауларны оештыручы** - коллегиаль киңәшмә органы түбәндәге составта:

- Җамалетдинов Илнур Минсәгыйть улы - Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе;
- Вилданов Муса Габделхак улы - Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары;
- Сабиров Айрат Атлас улы - Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе;
- Җиһаншина Э.Б. - Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы;
- Фәттахов Рәвгать Габбас улы - Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Лашман авыл җирлеге башлыгы.

Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru), мәгълүмат стендында һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында - 02.07.2026 ел **һәм анда түбәндәге мәгълүматлар бар иде:**

- проектка мәгълүмати материаллар исемлеге;
- проект буенча гавами тыңлаулар үткәрү тәртибе һәм сроклары;
- гавами тыңлауларда катнашучылар даирәсе;
- гавами тыңлаулар уздырыла торган территория;
- проект экспозицияләрен ачу урыны һәм датасы;

- проект экспозицияләрен үткәрү сроклары;
- экспозицияләрне карарга мөмкин булган көннәр һәм сәгатьләр турында мәгълүмат;
- гавами тыңлауларда катнашучыларның проектка кагылышлы тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертү тәртибе, сроклары һәм рәвеше;
- гавами тыңлауларда катнашучылар җыелышын үткәрү датасы, вакыты һәм урыны турында мәгълүмат;
- проект һәм аңа мәгълүмати материаллар урнаштырылган рәсми сайт турында мәгълүмат;
- гавами тыңлаулар башлану турында хәбәр урнаштырылган рәсми сайт турында мәгълүмат.

**Гавами тыңлаулар** Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Чирмешән районы, Лашман авылы территориясендә **уздырылды.**

**Гавами тыңлауларда катнашучыларның тәкъдимнәре һәм искәрмәләре** 02.07.2026 елдан 20.07.2026 елга кадәр кабул ителде.

**Гавами тыңлауларда катнашучылар:** тыңлауларда катнашкан затлар катнашучылар исемлегендә теркәлгән, ул беркетмәгә аерылгысыз кушымта булып тора.

Күрсәтелгән чор дәвамында гавами тыңлауларда катнашучылардан гавами тыңлаулар беркетмәсенә кертү өчен «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының «Лашман авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре» проектын тикшерү буенча» мәсьәләсенә кагылышлы тәкъдимнәр һәм искәрмәләр килмәде.

**Гавами тыңлаулар нәтиҗәләре:**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының «Лашман авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын тикшерү мәсьәләсе буенча гавами тыңлаулар узган дип танылды.

Гавами тыңлаулар башлану турында хәбәр итүне бастырып чыгару турындагы акт, проектны карауда катнашкан гавами тыңлауларда катнашучылар исемлеге кушымтада бирелә.

**Имзалар:**

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе ________________ И.М. Җамалетдинов

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесенең
беренче урынбасары _________________ М.Г. Вилданов

Татарстан Республикасы

Чирмешән муниципаль районы
Башкарма комитетының инфраструктура үсеше
бүлеге башлыгы ________________ Э.Б. Җиһаншина

Чирмешән муниципаль районының
Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре
палатасы рәисе _______________ А.А. Сабиров

Чирмешән муниципаль
районының Лашман
авыл җирлеге башлыгы _______________ Р.Г. Фәттахов